*ноябрь, 2021 ел*

# *Гимназия сулышы №2*

***25 нче гимназия укучылары газетасы***



Уку елының 2-чиреге укучыларның белем тирәнлеген билгеләүдә иң нәтиҗәле дип санала. Фәннәр буенча олимпиадаларның иң кызган чоры да бу. Түбән Кама муниципаль районы мәктәпләре арасында үткән олимпиадаларның нәтиҗәсе билгеле булды.

Менә алар гимназиянең уку алдынгылары- олимпиада призёрлары :Долганов Роман 6 Б –математика, косенко Ирина 4 Б, Пчелина Таисия7 Г, Ларина Дария10 А., - рус теле, Пшеворская Валерия 9 Б, Спиридонова Арина 11 А, Исанаева Азалия 11 А, - рус әдәбияты, Яркеев Илья-10 Б – җәмгыять белеме, Фазлеев Раиль 9 Б – информатика, Федотов Александр -10 А –тарих , Романова Светлана 7 Г, Божкова Виктория 8 А, Закирова Тамилла 8 А, Пшеворская Валерия 9 Б, Кузьмина Виктория 9 Б, Данилова Дарья 10 Б – дөнья халыклары мәдәнияте(МХК) фәннәре буенча .
Барыгызны да котлыйбыз , укучылар! Белем алуда яңа үрләргә итешегез!

**Шигърият яратучы**

Гайфутдинов Инсаф 6нчы б Б сыйныфында «4» ле һәм «5» ле билгеләренә укый. Ул аеруча математика, туган тел, рәсем дәресләрен ярата, буш вакытында китаплар укый, аеруча



Г.Тукайның шигырьләре ошый аңа. Инсаф ел саен гимназия укучылары арасында үткәрелүче шигырь конкурсында катнаша. Инсаф үзе дә хикәяләр, шигырьләр иҗат итәргә ярата. Газета укучыларга аның шигырен тәкъдим итәбез. Мухаметова Карина

**Гимназиядә укыйм**

Гимназиядә укыйм мин,
Быел алтынчы «б « ы да.
«4» ле, «5» леләргә укыйм,
Ударниклар рәтендә.

Математика, тарих
Дәресләрен яратам.
Туган телем – татар телен
Өйрәнәм һәм яратам.

Биология фәнен дә,
Кызыксынып өйрәнәм.
Физкультура дәресләрен
Һәрвакыт көтеп алам.

## Гимназиядә файдалы фандомат бар

Узган уку елында «Түбән Кама нефтехим акционерлар берләшмәсе» шефлар буларак гимназиядә пластик һәм алюминий савытларны эшкәртү өчен фандоматлар урнаштырган иде. Укучылар бу яңалыкны кызыксынып кабул иттеләр. Сыйныфлар арасында бер-берсен уздырып фандоматка пластик савытлар ташыдылар. Фандомат биргән талоннар буенча иң актив укучылар билгеләнде. Шундыйлардан 5 Г сыйныфы укучылары кинотетрга бушлай фильм карарга бардылар.

***Белеп торыгыз!***




***Россиядә яшәүче һәр кешегә елына 400 килограммм көнкүреш калдыгы туры килә!Ә илдәге чүп полигоннарының мәйданы 4 миллион гектарга җитә. Пластик савытларның 90 % фандомат ярдзмендә эшкәртеп, анны икенче чимал итеп файдаланып була.*** *Хуззятов Адель*



**Янгын сүндерүчеләр музеенда**

Балалар янгын сүндерүче һөнәренең бик җаваплы икәнен беләләр. Ә менә 62 нче янгын



сүндерү бүлегендә урнашкан музейга  баргач 1 нче а сыйныфы укучылары барысын да үз күзләре белән күрделәр. Укучыларны музейдагы шәһәребезнең кечерәйтелгән макеты  аеруча кызыксындырды. Беренчеләр Янгын сүндерүче машинасының баскычлары нинди биеклектә икәнен белделәр.



Экскурсовод балаларга янгын сүндерүченең экипировкасы , шлемы, өч килограммнан артык булга аяк киеме турында бик җентекләп сөйләде.



Шундый авыр экипировканы киеп  янгынны сүндерү өчен бик күп көч, тәвәккәллек кирәк икәнен белделәр беренчеләр.
Иконникова Лаура.

**Кванториумга экскурсия**

Шәһәрнең «Кванториум» – балалар технопаркы мәктәп укучылары арасында бик популяр.

Без кышкы каникул алдыннан «Кванториум»га бардык. Анда төрле мастер –класслар булды.Мин үзем анимацияле компьютер уеннарын яратам. Безгә мультимедиа программасында анимацияле фильм эшләргә өйрәттеләр. Үз йөрешле машиналарны





«Робот техникасы»

кабинетында җыйдык. Ә иң кызыклысы «Нейроквантум» кабинетында булды!



Без нанотехнология ярдәмендә кар бөртекләре ясадык. Әле Кыш бабайдан бүләкләр дә алдык! «Кванториум» һәм андагы хезмәткәрләр безгә бик ошады. Якупов Рамил

**Кадерле укучылар!**

Сезне Яңа 2022 ел белән котлыйбыз! Барыгызга да сәламәтлек, күңелле кышкы яллар телибез!

Редактор Хужҗәтов Адель
Проект җитәкчесе Шарапова Н.Н.